# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Югары Көек торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“4” декабрь 2025 ел. № 1

«Җәмәгать хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2025 елның 4 декабрендә «Сез 2026 елда Түбән Көек авыл җирлеге Югары Көек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, сиксән яшьтән өлкәнрәк гражданнар, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашучы) затлар һәм аларның гаилә әгъзалары, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Югары Көек авылы территориясен чистарту, үләннәр чаптыру, агач һәм куакларны кисү, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
2) Янгын куркынычсызлыгы буенча беренчел чараларны тәэмин итү ( Югары Көек авылының су чыгару башнясына насос сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)
3) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тору: (Югары Көек авылының урам юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алу һәм түшәү (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)), (Югары Көек авылының урамнарын кардан чистарту (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

Югары Көек авылы гражданнарының үзара салымыннан янга калдырылган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Янгын куркынычсызлыгы буенча беренчел чараларны тәэмин итү (Югары Көек авылында янгын инвентарен саклау өчен җайлаштырылган бинаны җылыту өчен төзелеш материаллары сатып алу (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 152 (бер йөз илле ике) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 78 ( җитмеш сигез) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 78 (җитмеш сигез) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Югары Көек авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. “Сез 2026 елда Түбән Көек авыл җирлеге Югары Көек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, сиксән яшьтән өлкәнрәк гражданнар, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашучы) затлар һәм аларның гаилә әгъзалары, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Югары Көек авылы территориясен чистарту, үләннәр чаптыру, агач һәм куакларны кисү, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

2) Янгын куркынычсызлыгы буенча беренчел чараларны тәэмин итү ( Югары Көек авылының су чыгару башнясына насос сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

3) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тору: Югары Көек авылының урам юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алу һәм түшәү (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү), (Югары Көек авылының урамнарын кардан чистарту (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

Югары Көек авылы гражданнарының үзара салымыннан янга калдырылган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Янгын куркынычсызлыгы буенча беренчел чараларны тәэмин итү (Югары Көек авылында янгын инвентарен саклау өчен җайлаштырылган бинаны җылыту өчен төзелеш материаллары сатып алу (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Югары Көек авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Югары Көек авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Галиәхмәтов Д.М.